СОВЕТ АЛБАЙСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Центральная, д.28, с. Албай, Мамадышский район, Республика Татарстан, 422176

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АЛБАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Үзәк ур., 28 нче йорт, Албай авылы, Мамадыш районы, Татарстан Республикасы,422176

тел.(факс): (85563) 3-05-08; e-mail: Alb.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

РЕШЕНИЕ
№ 4-29

КАРАР
15.11.2023ел.

Албай авыл җирлеге Советының 2005 елның 30 декабрендәге «Албай авыл җирлеге башкарма комитетын төзү турында» № 1-4 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында.

Район прокуратурасының 2023 елның 17 октябрендәге 02-01-19-2023 номерлы тәкъдимен карап, «Табигый дәвалау ресурслары, дәвалау-савыктыру урыннары һәм курортлар турында» Федераль законга, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе закон актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану хакында» 2023 елның 4 августындагы 469-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законнар, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы «Албайавыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Мамадыш муниципаль районы Албайавыл җирлеге Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Албай авыл җирлеге Советының 2005 елның 30 декабрендәге «Албай авыл җирлеге башкарма комитетын төзү турында» № 1-4 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 3.2 пунктындагы 28 нче абзацында “торак пункт территориясендә җирле әһәмияттәге дәвалау-сәламәтләндерү урыннарын һәм курортларны булдыру, үстерү һәм саклауны тәэмин итү, шулай ук " дигән сүзләрне төшереп калдырырыга.

2. Әлеге карарның 1.1 пункты 2024 елның 1 сентябреннән үз көченә керә дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында, Мамадыш муниципаль районының mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге караның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Албай авыл җирлеге башлыгы И.П. Крешковка йөкләргә.

Татарстан Республикасы Мамадыш
муниципаль районы Албай
авыл җирлеге башлыгы,
авыл җирлеге Советы рәисе И.П. Крешков